**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында**

Хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләренә ярдәм күрсәтү максатларында **карар бирәм**:

1. Россия Федерациясе Хәрби Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында 2023 елның 31 декабреннән соң контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнары өчен социаль ярдәм чарасы буларак 305 000 сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләргә, шул исәптән түбәндәге хәрби хезмәткәрләргә:

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә Татарстан Республикасы территориясеннән өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган;

Россия Федерациясе Оборона министрлыгының Татарстан Республикасында урнаштырылган хәрби частьләрендә хәрби хезмәткә чакыру буенча хәрби хезмәт узучы;

Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты яисә Казан шәһәренең контракт буенча хәрби хезмәткә сайлап алу пункты (1 разрядлы) тарафыннан алып барылган эш нәтиҗәсендә әлеге контрактны төзү турында карар кабул иткән Россия Федерациясе Оборона министрлыгы хәрби частьләрендә хәрби хезмәткә чакыру буенча хәрби хезмәт узучы яисә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә әлеге Указны үтәү белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә, шулай ук аны гамәлгә ашыру буенча башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 30 декабрь
№ 920